# Такмаклар

Әкәм-төкәм,
Чыгар мөгезең,
Чыгар мөгезең,
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен.





**Бу бармак – бабай,**
**Бу бармак – әби,**
**Бу бармак – әти,**
**Бу бармак – әни,**
**Бу бармак – нәни бәби,**
**Аның исеме – чәнчи.**

**Карга әйтә: “Кар-кар,**
**Мичтә бәлеш бар, бар.**
**Мичтән бәлеш алыр идем,**
**Өйдә кунак бар, бар”.**






**Болыт, болыт, килмә син,**
**Безнең юлны бүлмә син,**
**Син килгәч без куркабыз,**
**Өйгә кайтып китәбез.**

**Әби коймак пешерә,**
**Бабай ашап бетерә.**
**Тыңламаган малайларның**
**Артларыннан төшерә.**





**БАЛЫК КАП-КАП-КАП,
ЯР БАШЫНА ЯЛТЫРАП ЯТ.
ПЕСИ КИЛЕР-ТЕШНӘР,
КЕШЕ КИЛЕР-ИСНӘР.**

**ЯБАЛАК,ЯБАЛАК,**
**ЙӨРМӘ ЧЕБИ САГАЛАП.**
**ЧЕБИЕМНЕ БИРМӘМ.**
**КҮЗЕМӘ КҮРЕНМӘ, КЫШ!**





ЧЫПЧЫК, ЧЫПЧЫК,
ТӘРӘЗӘДӘН ОЧЫП ЧЫК.
АЛИЯНЕҢ ӨСТЕНӘ
МАТУР КҮЛМӘК БИРЕП ЧЫК.


**КАРГА КИЛӘ, КАЗАН АСА,**
**ТОРНА КИЛӘ, ТОЗ САЛА.**
**ПЕСНӘК КИЛӘ, ПЕШЕРӘ.**
**ЧЫПЧЫК КИЛӘ, ТИКШЕРӘ.**
**ӘДИП АШАП БЕТЕРӘ.**
**КАП ТА КОП!**





Тук, тук, тукран,
Тукылдатып утырам,
Агачтагы кортларның
Барсын чүпләп бетерәм!

**ҖИЛӘК ҖЫЯМ, КАК КОЯМ,**
**ДӘҮ ӘНИГӘ БҮЛӘККӘ.**
**МОНДА ҖИЛӘК КҮП ИКӘН.**
**АЮ-БҮРЕ ЮК МИКӘН.**



Балам бии, багыгыз,
Кесәгезне кагыгыз,
Кәнфитегез булмаса,
Магазиннан алыгыз.



Кибәргә элгән керләрем
Җилгә очып китмәсен.
Авызыңны бик зур ачма,
Карга кереп китмәсен.





Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр әтәчләр.
Безнең авыл егетләре –
Пешмәгән пәрәмәчләр.



**СТАКАНГА СЫЕР ТӨШКӘН,**
**НИЧЕК БАТЫП ҮЛМӘГӘН.**
**КӨТҮЧЕСЕ ШУНДА БУЛГАН,**
**НИЧЕК АНЫ КҮРМӘГӘН?**

**ТӘК-ТӘК-ТӘКҮШКӘ.**
**ТӘКӘ КЕРГӘН ИНЕШКӘ.**
**КҮРМӘДЕНМЕ ДӘДҮШКӘ,**
**СУЙМАДЫНМЫ БӘЛЕШКӘ,**
**СУЙГАН БУЛСАН БӘЛЕШКӘ,**
**МИНЕ ЧАКЫР ӨЛЕШКӘ.**







**ЧӘЙ ЭЧӘБЕЗ БАЛ БЕЛӘН,**
**БАЛА-ЧАГАЛАР БЕЛӘН.**
**БАЛА-ЧАГА АЛТЫ ҖАН.**
**ҖИДЕНЧЕСЕ ХАКИМҖАН.**

**АЙ ДИЛӘР, ВАЙ ДИЛӘР,**
**БУ АБЗЫЙ БИК БАЙ ДИЛӘР.**
**БУ АБЗЫЙНЫҢ КАПЧЫГЫНДА**
**БАЛЛЫ ПРӘНИК БАР ДИЛӘР.**



**АГЫЙДЕЛДӘ БЕР БАКА**
**БЕР БАТА ДА , БЕР КАЛКА.**
**ШУНЫ СИҢА ОХШАТЫП,**
**КЙЛЕП ЭЧЛӘРЕМ КАТА.**



**СИН МАТУР, СИН ЧИБӘР,**
**СИҢА КАРАП ТУЙМЫЙЛАР.**
**НИГӘ СИНЕ ЗООПАРККА**
**МАЙМЫЛ ИТЕП КУЙМЫЙЛАР?**





**КӨЗГЕГӘ КАРЫЙМ ӘЛЕ,
ЧӘЧЕМНЕ ТАРЫЙМ ӘЛЕ,
ӘБИЛӘРГӘ БЕР АТНАГА
КУНАККА БАРЫЙМ ӘЛЕ.**

**Әллүкәй, бәллүкәй,**
**Шакир һаман бәләкәй,**
**Бармак белән тисәң дә,**
**Әткәсенә әләкләә.**



**Җылак, җылак,**
**Җыртык колак.**
**Мич башында**
**Пешкән колак.**

ИСӘНМЕСЕЗ, САУМЫСЫЗ,
НИГӘ КӘҖӘ САУМЫЙСЫЗ.
ӘТӘЧЕГЕЗ КҮКӘЙ САЛГАН,
НИГӘ ЧЫГЫП АЛМЫЙСЫЗ?

ӘТӘЧ МЕНГӘН КИРТӘГӘ
КИКРИКҮК ИТӘРГӘ.
ӘТӘЧКӘ ДӘ ХӘБӘР КИЛГӘН
АРМИЯГӘ КИТӘРГӘ.





**ИКЕ САРЫК ЮЛГА ЧЫККАН,**
**КУЛЛАРЫНДА ЧУМАДАН.**
**ИРЕННӘРЕН БУЯГАННАР,**
**Ә БИТЛӘРЕ ЮМАГАН.**

**АЛАЙ ИТӘЛӘР АНЫ,**
**БОЛАЙ ИТӘЛӘР АНЫ**
**ЧАБАТАГА ТЫЧКАН ҖИГЕП,**
**ГУЛЯТЬ  ИТӘЛӘР АНЫ.**





**БАКА, БАКА,БАКЫРГАН,**
**БАКА КУНАК ЧАКЫРГАН.**
**КУНАКЛАРЫ КИЛМӘГӘЧ,**
**ТЫШКА ЧЫГЫП АКЫРГАН.**